**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

---

**РЕШЕНИЕ**

**22.11.2017 г.**

**КАРАР**

**№68**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2018 нче елга һәм 2019,2020 нче еллар план чорына бюджеты турында карар проекты кабул итү турында

"Россия Федерациясенлә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Иске Имән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Иске Имән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2018 елга һәм 2019, 2020 елларның план чорына бюджеты турында" карар проектын беренче укылышта кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2018 нче елга һәм 2019, 2020 нче елларга план чорына бюджеты турында" карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:
   1. Исламова Р.Ә. –төркем җтәкчесе
   2. Галиев Д.З. - төркем әгъзасы
   3. Саттаров А.Р .- төркем әгъзасы
   4. Сабитов Ә.Н.- төркем әгъзасы
   5. Шакиров А.Ә.- төркем әгъзасы
4. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре: Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Иске Имән авылы, Мулланур Вахитов урамы, 36в йорт адресына язмача җибәрелә дип билгеләргә.

5. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2018 нче елга һәи 2019, 2020 нче елларның план чорына бюджеты турындагы карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2017 елның 5 нчы декабрендә 14.00 сәгатькә билгеләргә.
6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә, аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советы каравына 2017 елның 17 декабренә кадәр кертергә.
7. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO TATARSTAN. RU) һәм Татарстан Республикасы "Сарман муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

Иске Имән авыл җирлеге Советы рәисе: Р.Ә.Исламова